| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.11.2021 Казан ш. № 339-68/тэ-2021

Югары Ослан авылы, Автодорожная урамы, 2 адресы буенча урнашкан җылылык энергиясе чыганагыннан (котельня) кулланучыларга «Таткоммунэнерго» республика җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыятеннән җиткерелә торган җылылык энергиясе (егәрлеге) өчен 2022 елга тарифлар билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Югары Ослан авылы, Автодорожная урамы, 2 адресы буенча урнашкан җылылык энергиясе чыганагыннан (котельня) кулланучыларга «Таткоммунэнерго» республика җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыятеннән (алга таба – «Таткоммунэнерго» РҖБ» АҖ) җиткерелә торган җылылык энергиясе (егәрлеге) өчен әлеге карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2022 елның 1 гыйнварыннан 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач гамәлгә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
23.11.2021 № 339-68/тэ-2021
карарына кушымта

Югары Ослан авылы, Автодорожная урамы, 2 адресы буенча урнашкан җылылык энергиясе чыганагыннан (котельня) кулланучыларга «Таткоммунэнерго» РҖБ» АҖ тарафыннан җиткерелә торган җылылык энергиясе (егәрлеге) өчен 2022 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланган пар | | | | Әче һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | Югары Ослан муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | Югары Ослан авылы, Автодорожная урамы, 2 адресы буенча урнашкан җылылык энергиясе чыганагыннан (котельня) кулланучыларга «Таткоммунэнерго» РҖБ» АҖ тарафыннан | | | | | | | |
| 1.1 | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 1568,93 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 1666,20 | - | - | - | - | - |
| 1.2 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 1882,72 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 1999,44 | - | - | - | - | - |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге